**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№590**
**11.02.2020**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны карау һәм саклау турында» 2007 елның 29 маендагы 1978 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга һәм алардагы табигый объектларга китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы Карары һәм Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны карау һәм саклау турында» 2007 елның 29 маендагы 1978 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2007 елның 14 августындагы 2924 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 3238 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карар преамбуласында:

- «2002 елның 20 гыйнварындагы Федераль закон» сүзләрен «2002 елның 10 гыйнварындагы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

- «киселүче яшел утыртмаларның бәясен каплау» сүзләре үз көчен югалткан дип таныргa;

2) 1 пунктта «киселүче яшел утыртмаларның һәм компенсацион яшелләндерүне башкаруның бәясен исәпләү методикасын, 2 нче кушымтада каралганча» сүзләрен «яшел утыртмаларны кисү өчен түләүне исәпләү методикасын, 2 нче кушымтада каралганча» сүзләренә алмаштырырга;

3 ) 1 нче кушымтада:

- 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшел утыртмалар - табигый һәм ясалма рәвештә барлыкка килә торган агач, куак һәм үлән үсемлекләре (паркларны, бульварларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәклекләрне, шулай ук аерым торучы агачларны һәм куаклыкларны да кертеп).

Табигый формада компенсацион яшелләндерү - юк ителгән яки зыян күргән яшел утыртмаларга алмашка яңаларын үстерү.

Акчалата формада компенсацион яшелләндерү - яшел утыртмаларны санкцияләнгән кисү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланган методика буенча исәпләнгән акчалата компенсация.

Яшел утыртмаларга китерелгән зыянны каплау - яшел утыртмаларны санкцияләнмәгән кисү, зыян китерү, юк итү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары белән расланган методика буенча исәпләнгән акчалата компенсация.

Яшел утыртмаларга зыян китерү - агач һәм куакларның ябалдашына, кәүсәсенә, ботакларына, аларның тамыр системасына үсеше тукталуга китерми торган зыян китерү. Зыян китерү булып түбәндәгеләр тора: ботакларга, тамыр системасына механик зыян китерү, тамырның бөтенлеген бозу, шулай ук агач-куак үсемлекләрен яисә тамыр зонасындагы туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату, ут төртү яки башка зыян китерү.

Яшел утыртмаларны юк итү - агач һәм куакларга үсеше тукталуга китерә торган зыян китерү, агач-куак үсемлекләренең һәлак булуы, шулай ук аларны кисү.

Агачларны кисү - агачлар һәм куаклыклар киселә торган тиешле җирләрдәге яки җир участокларындагы агачларны кисү.

Ябалдашларны кисү (яшәртү өчен кисеп кыскарту) – үзлегеннән яшәрүгә сәләтле агачларның ботакларын һәм кәүсәсен 3,5-6,5 м биеклектә кисү»;

- 2.11, 2.12, 2.14, 2.15, 3.12 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

- 8.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.3. Компенсацион яшелләндерү, мәнфәгатьләрендә яшел утыртмаларны кисү, күчереп утырту планлаштырыла торган яисә яшел утыртмаларны кисү, күчереп утырту, зыян китерү яки юк итү алар гаебе аркасында башкарылган физик зат, шәхси эшмәкәр, юридик зат тарафыннан табигый яки акчалата формада башкарыла. Шул ук вакытта өстенлек компенсацион яшелләндерүнең табигый формасына бирелә.

8.3.1. Табигый формада компенсацион яшелләндерү шәһәрнең яшел утыртмаларга зыян китерү яки юк итү планлаштырыла торган яисә гамәлгә ашырылган өлешендә, юк ителгән яшел утыртмаларга алмашка тигез кыйммәтле яки аннан да кыйммәтрәк төрләрен (төркемнәрен) утырту юлы белән, түбәндәге очракларда башкарыла:

- корыган һәм авария хәлендәге яшел утыртмаларны кисү;

- санитар кисүләрне үткәргәндә (үсеше артта калган тәбәнәк декоратив үсемлекләр, яшь үсентеләр, куе утыртмалар бетерелә);

- яшел утыртмалар белән капланган торак һәм торак булмаган биналарда норматив яктылык режимын тәэмин иткәндә (тиешле дәүләт органнары күрсәтмәсе буенча);

- СНиП бозып утыртылган агач һәм куакларны кискәндә;

- инженерлык коммуникацияләренең авария эшләрен үткәргәндә һәм аварияне һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә.

8.3.2. Кискән өчен акчалата формадагы компенсация табигый формада компенсацион яшелләндерүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда һәм яңа төзелештә гамәлгә ашырыла.

Кискән өчен акчалата формада компенсация Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланган яшел утыртмаларны кисү өчен түләүне исәпләү методикасы буенча исәпләнә.

8.3.3. Мәнфәгатьләрендә яшел утыртмаларны кисү, күчереп утырту планлаштырыла торган физик зат, шәхси эшмәкәр, юридик зат гариза буенча, табигый формадагы компенсацион яшелләндерүне кискән өчен акчалата формадагы компенсациягә алмаштырырга хокуклы.

8.3.4. Яшел утыртмаларны санкцияләнмәгән кискәндә, зыян китергәндә, юк иткәндә Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары белән расланган методика нигезендә яшел утыртмаларга китерелгән зыян күләме исәпләнә.»

- 8.4 пунктта икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән срок узганнан соң, яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу комиссиясенең карары нигезендә, заказ бирүченең гаризасы буенча агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларны кисүгә һәм утыртуга рөхсәт озайтыла.»;

- түбәндәге эчтәлектәге 8.5 пунктны өстәргә :

«8.5. Табигый формада компенсацион яшелләндерү түбәндәге күләмнәрдә үткәрелә:

1) бер киселгән агач урынына өч агачка кадәр;

2) бер киселгән куак урынына биш куакка кадәр;

3) юк ителгән үлән үсемлеге (газон) мәйданының бер квадрат метрына алмашка торгызылган үлән үсемлеге мәйданының бер квадрат метры.»;

- 9.1 пунктта җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

- 9.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.2. Яшел утыртмаларның урнашу урынын тикшерү акты нигезендә, агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларны кисүгә һәм утыртуга рөхсәт әзерләнә. Яшел утыртмаларны кисү өчен түләү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланган методика нигезендә билгеләнә.»;

- 9.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4. Инженерлык коммуникацияләренең сак зоналарына керә торган инженерлык коммуникацияләрен капиталь яки агымдагы ремонтлаганда яшел утыртмаларны кискән өчен китерелгән зыян кайтарылырга тиеш түгел, ә ремонт эшләре барышында бозылган газоннарны һәм чәчәклекләрне яңадан торгызу заказ бирүче акчалары хисабына башкарыла.»;

- 9.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.5. Инженерлык коммуникацияләренең сак зонасыннан читтә эшләр башкару зонасында үсә торган яшел утыртмаларны кискәндә, яшел утыртмаларны кисү өчен түләү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланган методика нигезендә билгеләнә»;

- 9.7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

- 11.1 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - карап тоту һәм ремонтлау процессында башкарыла торган барлык очракларда да, агачларны һәм куакларны кисүне һәм күчереп утыртуны әлеге кагыйдәләр таләпләренә туры китереп гамәлгә ашырырга, компенсацион яшелләндерүне башкарырга;»;

- 11.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.6. Яшел утыртмаларны санкцияләнмәгән кисү, зыян китерү, юк итү өчен китерелгән зыян Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары белән расланган методика нигезендә кире кайтарылырга тиеш»;

4 ) 2 нче кушымтада:

- кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшел утыртмаларны кисү өчен түләүне исәпләү методикасы»;

- 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Методика яшел утыртмаларны санкцияләнгән кисү өчен шәһәр бюджетына кертелергә тиешле түләүләрне исәпләү өчен билгеләнгән.»;

- 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Методика яшел утыртмаларны санкцияләнгән кисү өчен түләүне исәпләгәндә кулланыла.»;

- 2 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

- 3 бүлек исемендә «киселәчәк яшел утыртмаларның бәясен билгеләү өчен. Компенсацион яшелләндерү» сүзләрен «яшел утыртмаларны кисү өчен түләүне билгеләү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.1 пунктның 1 абзацында «Шәһәрнең киселәчәк төп типтагы яшел утыртмаларының бәясен исәпләү өчен» сүзләрен «яшел утыртмаларны кисү өчен түләүне исәпләү өчен» сүзләренә алмаштырырга»;

- 3.2 пунктның 7 абзацында «базис» сүзен «база» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.2 пунктның 8 абзацында «базис» сүзен «база» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.2 пунктның 9 абзацында «базис» сүзен «база» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.4 пунктта «киселәчәк ... бәясен исәплəгәндә» сүзләрен «кисү өчен түләүне исәпләгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.6 пунктта «киселәчәк ... бәясен исәпләгәндә» сүзләрен «кисү өчен түләүне исәпләгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

- 4 бүлек исемендә «киселәчәк ... бәясе» сүзләрен «кисү өчен түләүне исәпләү» сүзләренә алмаштырырга;

- 4.1 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Агач кисү өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Пвд = Бс_j \text{ х } Кж \text{ х } Кф \text{ х } Ии, \text{ монда»}$$

- 4.1 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пвд - агач кисү өчен түләү күләме;»;

- 4.1 пунктының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ии - төзелеш объектлары буенча төзелеш-монтаж һәм сафка кертү-көйләү эшләренең законда билгеләнгән тәртиптә расланган смета бәясен үзгәртү индексы»;

- 4.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

- 4.3 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Куак кисү өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Пвк = Бс_j \text{ х } Кж \text{ х } Кф \text{ х } Ии, \text{ монда»}$$

- 4.3 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пвк - куак кисү өчен түләү күләме;»;

- 4.3 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ии - төзелеш объектлары буенча төзелеш-монтаж һәм сафка кертү-көйләү эшләренең законда билгеләнгән тәртиптә расланган смета бәясен үзгәртү индексы»;

- 4.4 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Куаклардан, лианалардан торган тере киртәләрне кисү өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Пвжи = Бс_j \text{ х } Кж \text{ х } Кф \text{ х } Ии, \text{ монда»}$$

- 4.4 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пвжи - куаклардан, лианалардан торган тере киртәләрне кисү өчен түләү күләме;»;

- 4.4 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ии - төзелеш объектлары буенча төзелеш-монтаж һәм сафка кертү-көйләү эшләренең законда билгеләнгән тәртиптә расланган смета бәясен үзгәртү индексы»;

- 4.5 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Чәчәклекне юк итү өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Пуцв = Бс_j \text{ х } Кж \text{ х } Кф \text{ х } Ии, \text{ монда»}$$

- 4.5 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пуцв - чәчәклекне юк итү өчен түләү күләме;»;

- 4.5 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ии - төзелеш объектлары буенча төзелеш-монтаж һәм сафка кертү-көйләү эшләренең законда билгеләнгән тәртиптә расланган смета бәясен үзгәртү индексы»;

- 4.6 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Газонны юк итү өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Пуг = Бсј x Кж x Кф x Ии, монда»

- 4.6 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пуг - газонны юк итү өчен түләү күләме;»;

- 4.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ии - төзелеш объектлары буенча төзелеш-монтаж һәм сафка кертү-көйләү эшләренең законда билгеләнгән тәртиптә расланган смета бәясен үзгәртү индексы»;

- 4.7, 4.8 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

- 5 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев